Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлеге Сәләнгеш авылында
гражданнар җыены КАРАРЫ

«16» ноябрь 2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авыл җирлеге Сәләнгеш авылы гражданнары җыены
КАРАР ИТТЕ**:**

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авыл җирлеге Сәләнгеш авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан тыш, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, СВОда катнашучылардан, 90 яшь тутыручылардан тыш, 2025 елда 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү;
- янгынга каршы резервуарларны (янгын сулыкларын), янгын пирсларын төзү, ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- ремонт, коймалар кору, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү».

2. Халык җыенының нәтиҗәләрен «Интернет «мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авылының мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлегенең әлеге карарын Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыены рәисе: А.Н. Пинин

Сәләнгеш авыл җирлеге башлыгы: А.Н. Пинин